ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16 сентября 2016г. № 4814

Башкарма комитетның «Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү турында» 2016 елның 12 июлендәге 3538 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәне караганнан соң, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү турында» 2016 елның 12 июлендәге 3538 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтада:

- 2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

«Компенсация өчен мөрәҗәгать иткән көнгә гаиләнең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы зурлыгыннан азрак яки аңа тигез булган очракта компенсация түләнә.»;

- 6 пунктның 13 пунктчасын төшереп калдырырга;

- 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Компенсация түләү Башкарма комитетның тиешле район Хакимияте тарафыннан Башкарма комитетның финанс идарәсенә, раслаучы документларны теркәп, компенсация түләүләрен финанслау өчен тапшырылган заявка нигезендә һәм комиссия карары чыккан айның 30 числосына кадәр гариза бирүченең банк счетына гамәлгә ашырыла.»

- 10 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

2) 2 нче кушымтада:

- 7 пунктның 5 пунктчасын «мәгълүматны» сүзләреннән соң «карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә» сүзләре белән тулыландырырга;

3) 3 нче кушымтада:

1) Р.Н. Вафинны чыгарырга;

2) өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү буенча шәһәр Башкарма комитеты Комсомол районы Хакимиятенең комиссия составына комиссия рәисе, Комсомол районы Хакимияте Башлыгы Кислов Александр Ивановичны кертергә.

2. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы Ә.А. Галиәкбәровага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитетның районнар Хакимияте Башлыклары И.Н. Галимовка, А.И. Кисловка, Р.М. Усмановага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин